**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАБАР ЧЕРКЕНЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

21 сентябрь, 2020 ел №4

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында 2020 елның 20 июлендәге, № 236-ФЗ Федераль законның 1 статьясындагы 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Табар Черкене авыл җирлеге Советың 2018 елның 10 сентябрендәге 78 номерлы “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Табар Черкене авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” карары белән расланган “Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Табар Черкене авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.6 пунктана түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:

«муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы вәкаләтләре гражданнар җыены тарафыннан гамәлгә ашырыла торган җирлектә инициативалы проектларны тәкъдим итү, әзерләү, сайлап алу һәм тормышка ашыру мәсьәләләре буенча.».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Табар Черкене авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Табар Черкене авыл җирлеге**
**Башлыгы**
**Табар Черкене авыл җирлеге Советы**
**Рәисе** **Р.Х. Ибәтуллин**